ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» 1993 елның 13 июлендәге 1934-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 19 июлендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 6 – 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 4; 2008, № 1; 2011, № 11 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш); 2021, № 93 (I өлеш); 2023, № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 1 өлешендәге өченче абзацында «ветеринария-санитария ягыннан» сүзләрен «ветеринария ягыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяның 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«15) «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $19^2$ статьясындагы 3 пунктында (алга таба – «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законы) күрсәтелгән очраклардан тыш, федераль башкарма хакимиятнең ветеринария күзәтчелеге өлкәсендәге органы тарафыннан зоосанитария статусын билгеләүдә катнашу.»;

3) 18 статьяда:
а) 1 өлештә:
дүртенче абзацта «терлекләрне күчерүнең һәм чалуның, терлек продукциясен эшкәртүнең, саклауның һәм сатуның билгеләнгән ветеринария-санитария кагыйдәләрен» сүзләрен «ветеринария кагыйдәләрен» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «ветеринария-санитария ягыннан» сүзләрен «ветеринария ягыннан» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «ветеринария-санитария ягыннан» сүзләрен «ветеринария ягыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) 19 статьяда:

а) 1 өлештә татарча текст үзгәрешсез кала;

б) 2 өлештә татарча текст үзгәрешсез кала.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 – 3 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 – 3 пунктлары 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                        Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 05 март
№ 11-ТРЗ